СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с. Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**« 21 » август, 2019 ел** **№ 115**

## “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүне әзерләү тәртибе турында " Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы федераль законның 25.1 статьясын, 2004 елның 27июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Иске Кырлай” муниципаль берәмлеге Уставы статьяларын тормышка ашыру максатында Иске Кырлай авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендә чыккан “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүне әзерләү тәртибе турында" гы 79 нче номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)1.6. пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа җирлек төзү турында халык инициативасын алга сөрү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия булган халык саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча»;

2) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 3.5. Гражданнар җыены торак пункт яки җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокукка ия. Торак пунктта әлеге торак

пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә җыелу мөмкинлеге булмаса, әлеге торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

2.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Арча муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.*Карарның үтәлешен контрольдә тотуны* Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

*Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы* Ф.Г.Сиражетдинов